# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Дусай Кичү авыл җирлегенең 2022 елда үзара салым кертү турында

«19» ноябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге Дусай Кичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, 1-2 төркем инвалидлар,балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда үзара салым 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Дусай Кичү торак пункты зираты коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

3. Җыенның нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://menzelinsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче: ____________ Нәҗметдинов З. И.
(имза) (имзаны киңәйтү)

Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ____________ Нәҗметдинов З. И.
(имза) (имзаны киңәйтү)